| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«21» май 2025 г. г. Альметьевск № 365

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 29 ноябрендәге 118 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2025 елның 26 мартындагы 02-01-24 номерлы протесты нигезендә,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2006 елның 29 ноябрендәге 118 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының муниципальара хезмәттәшлектә катнашу тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтаны түбәндәге эчтәлекле 2.1 бүлек белән тулыландырырга:

«2.1. Муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында катнашу формалары

2.1.1. Муниципальара хезмәттәшлек түбәндәге формаларда гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль берәмлекләрнең муниципаль берәмлекләр берләшмәләрендә әгъза булу;

2) муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен, муниципальара басма массакүләм мәгълүмат чарасын һәм челтәр басмасын булдыру;

3) муниципаль берәмлекләр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар төзү;

4) килешүләр һәм шартнамәләр төзү.

2.1.2. Муниципаль берәмлекләр берләшмәләре, муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре, муниципаль берәмлекләр тарафыннан гамәлгә куелган коммерциягә карамаган оешмалар җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә ия була алмый.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Туманова Г.П.).

Муниципаль район Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Е. Әфләтунова